РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
БОЛЬШЕШИНАРСКИЙ
СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, дом 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
15.09.2022

КАРАР
№20-п

Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл
Башкарма комитетының 06.04.2020елда
11-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлегенең салым
чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым
чыгымнарын бәяләүне үткәрү тәртибенә
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 15.06.2022 ел, №1081 РФ Хөкүмәте Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл башкарма комитетының“Олы Шыңар авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 6нчы апрелендә 11-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1.3 пунктында «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 3.3 пунктның икенче абзацында «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3.3 пунктның өченче абзацын киләсе редакциядә бәян итергә:
"бирелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗы, ул ташламаларга хокуклы түләүчеләр саны нисбәте һәм ташламаларны куллану хокукына ия булган түләүчеләр саны яки 5 еллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән характерлана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов